**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫАПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

21 октябрь 2024 ел № 143

**Иске Йомралы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 30.09.2024 елгы 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Советының «Иске Йомралы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 20 гыйнварындагы 86 номерлы карары белән расланган Иске Йомралы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8.3 пунктның 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:
«5) белеем һәм квалификация турында документ;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Иске Йомралы авылҗирлегебашлыгы,**
**Иске Йомралы авылҗирлеге Советы Рәисе Р.А.Муратов**